ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2021 с.Старое Дрожжаное № 94

Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 03 сентябрендәге 379 номерлы карары белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктындагы икенче баганада 6 пунктчаны төшереп калдырырга;

2.6 пунктның икенче баганасында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;»;

түбәндәге эчтәлекле 3-7 пунктчалар белән тулыландырырга:

«3) 14 яшькә җитмәгән гариза бирүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

4) Мөрәҗәгать итүче һәм/яки аның гаилә әгъзалары өчен никах теркәү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

5) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

6) Никахны өзү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

7) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия Пенсия фондына.»;

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А.Сатдинов